# Г.ТУКАЙНЫҢ “ХАЛЫК ӘДӘБИЯТЫ” ЛЕКЦИЯСЕНӘ БЕР КАРАШ

Җамалиева Л.Ф., филология фәннәре кандидаты, Казан федераль (Идел буе) университетының Филология һәм сәнгать институты татар әдәбияты тарихы кафедрасы доценты

2011 нче ел Республикабызда Г.Тукай елы дип игълан ителгән иде. Билгеле инде, хәзерге вакытка кадәр татар халкының күренекле шагыйре Г.Тукай иҗаты бик киң планда өйрәнелгән өлкә. Әмма бу бай иҗат бүгенге көндә дә тикшеренүчеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итеп тора. Хезмәтебезнең максаты – Г.Тукайның татар фольклористикасы тарихындагы урынын билгеләү. Г.Тукайның бу өлкәдәге эшчәнлеген берничә юнәлешкә бүлеп карарга мөмкин: беренчедән, Г.Тукай үзе халык авыз иҗаты әсәрләрен бик күп белүче информант, халык чичәне, икенчедән, Тукай – халык иҗатын җыючы һәм аны пропагандалаучы, өченчедән, Г.Тукай – татар фольклорының теоретик нигезләрен билгеләүчеләрнең берсе һәм шул ук вакытта үзенең әсәрләрендә фольклор мөмкинлекләреннән бик уңышлы файдаланучы.

Г.Тукайның халык иҗатына мәхәббәте бала чактан ук башлана: “Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия кыйлына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне беткәнче яргач, тагын җырлый идем. Мәдрәсәдә үк мине җырчы диләр иде.” [Тукай, 1985:185-186].

Шагыйрь 1910 елның 15 апрелендә Казандагы Шәрык клубында “Халык әдәбияты” дип аталган лекция укый. Лекциянең кереш өлешендә үк Г.Тукай үзенең бу өлкәдә махсус белемле галим булмавына басым ясый: “халык әдәбияты хакында үземнең белгән вә хис иткән кадәр фикерләремне

сөйләргә җәсарәт итәм (батырчылык итәм) дип белдерә ” [Тукай, 1985:166]. Лекция шагыйрьнең “Тәфкилев көе”, “Ашказар көе”, “Сак-Сок көе”, “Касыймский Ибырай”, “Җизнәкәй”, “Башмак көе” халык җырының тарихын сөйләүдән башланып китә.

Алга таба, мәкаләнең төп өлешендә шагыйрь фольклорга билгеләмә бирә: “Халык әдәбияты, халык шигырьләре дип инша итүче шагыйре беленмәгән, яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә масалларга әйтеләдер”. Г.Тукай халык авыз иҗатының төп үзенчәлекләрен билгели. Халык иҗатының синкретик характерда булуы, аның коллектив иҗат нәтиҗәсе булуы, телдән иҗат ителүе һәм буыннан буынга тапшырылуы, вариантлылыгы, халык иҗаты әсәрләре белән авторы билгеле әсәрләр арасындагы аермалар турында бик кызыклы фикерләр әйтә [Тукай, 1985:170]. Лекциядә халык җырлары, аларның поэтик үзенчәлекләрен, кулланылыш даирәсен һәм таралу мөмкинлекләрен ачыклауга бик зур урын бирелгән. Татар халык җырлары турында төрле чорларда язылган фәнни хезмәтләрнең барысында дип әйтерлек галимнәрнең Г.Тукайның “Халык әдәбияты” хезмәтенә мөрәҗәгать итүләрен күрергә мөмкин. Бик күп мәктәпләрнең музыка кабинетларындагы стендларда Тукайның “Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр” яки “Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер. Бу бертөрле сихерле көзгедер. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр” кебек сүзләрен укырга була. Тукайның халык җырларының башкарылу формасына да игътибар итүен әйтергә кирәк. Аны бигрәк тә йола җырларындагы кара-каршы җырлашу кызыксындыра. Бу урында шагыйрьнең татар халык җырларын кыргыз халык җырлары белән дә чагыштыруы бик үзенчәлекле. Әдип халык җырларындагы ике буынлы параллелизмга да үзенчә аңлатма бирә, татар җырларының тәрҗемәдә бөтенләй башка мәгънә алачагына да

игътибарны юнәлтә. Шул ук вакытта шагыйрь өчен җырларның музыкаль ягы да әһәмиятле. Ул җырның тыңлаучыга тәэсире аны башкаручыга бәйле икәнен дә ассызыклап китә һәм башка милләт кешеләренең татар җырын башкара алуларына шик белдерә: “Безнең көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек, шуның безнең күңелгә охшарына күңел ышанмый. Көемезнең алтынын кояр шикелле тоела” – дип яза.

Тукайның әлеге хезмәтендәге тагын бер әһәмиятле фикер – ул да булса халык әдәбиятының киләчәктә язма әдәбиятка нигез булачагын күрсәтүе. “Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр” – ди Тукай. [Тукай, 1985:177]. Шагыйрь татарлар гына түгел, инде русларда халык иҗатына нигезләнеп язылган әсәрләрне Пушкин, Кольцов иҗатларыннан табарга мөмкин дип белдерә һәм мондый шигырьләрне “соңгый җырлар” дип атый. Г.Тукай җырларның тел үзенчәлекләрен һәм гомумән телне саклаучы чыганак булуларын ассызыклый: “чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җыруларыннан гына табып була.” [Тукай, 1984:184].

Г.Тукай, халык җырлары турындагы күзәтүләрен тезислар формасында биреп, бездә кызыксыну уята һәм үзенең бу өлкәдә белеме җитмәүне сәбәп итеп, сүзне туктата. Шул рәвешле, Г.Тукайның “Халык әдәбияты” лекциясе татар халык җырларын фәнни-теортик яктан өйрәнүгә багышланган беренче хезмәтләрнең берсе дип әйтергә нигез бар. Билгеле, шагыйрьнең халык авыз иҗаты юнәлешендәге хезмәтләре әлеге лекция белән генә чикләнми. Аның халык җырларын җыеп, туплап бастырган “Халык моңнары” җыентыгы аерым бер тикшеренү темасы булырлык. Шагыйрьнең фольклордагы сюжетларга нигезләнеп язылган “Шүрәле”, “Су анасы”, “Кәҗә белән Сарык” һ.б. әсәрләре дә аның халык иҗатыннан илһам алуын күрсәтә. Күп еллар дәвамында экиятләрне тикшергән фольклорчы Ленар Җамалетдинов татар әдәбиятында әдәби экиятләр иҗат итү Г.Тукайның 1907 нче елда иҗат ителгән мәшһүр “Шүрәле” поэмасыннан башлана дип саный [Җамалетдинов,

1992: 157]. Шул ук вакытта, Г.Тукай моңарчы халыкның хыял бишегендә генә тибрәлгән мифологик образ Шүрәлене әдәби герой буларак популярлаштыра. Замана укучысы Шүрәлене Тукай тудырган образ дип саный. Татар укучысының шүрәле хакындагы тәүге күзаллаулары шушы әсәр белән бәйле. Әсәрнең беренче басмасына Г.Тукай «Өмит юк түгел әле: ихтимал, үз арабыздан маһир рәссамнар чыгып, Шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кылынган урманнарны – һәммәсен тәрсим кылып чыгарырлар» дигән юлларны язган. Шагыйрьнең бу өметләре тормышка ашты. Күренекле рәссамнар Ф.Әминев һәм Б.Альменовлар Шүрәленең Тукай күрергә теләгән рәсемен иҗат иттеләр. Рәссам һәм сынчы Б.Урманче акварельләрдә һәм скульптурада «Шүрәле циклы» әсәрләре иҗат итте. Композитор Ф.Яруллин шагыйрь Ә.Фәйзи либреттосына нигезләнеп шул исемдәге балет язды.

Соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрдән М.Галиевнең «Шүрәле һәм җил» шигырендә, Р.Миннуллинның «Шүрәлеләр турында, Малайлар турында, Тылсынчы бабай турында һәм тагын Шүрәлеләр турында кечкенәкият» әсәрләрендә дә шүрәле образы шактый тулы тасвирлана. Шүрәле образын Ф.Яруллин, ЛЛеронның соңгы вакытта иҗат ителгән әсәрләрендә дә күрергә була. Ф.Яруллинның «Шүрәленең авылда күргәннәре» әкиятендә шүрәлеләр һәм кешеләр тормышын, яшәү шартларын чагыштыру аша, бүгенге авылга төрле начар гадәтләр үтеп керүен, кешеләрнең әхлакый яктан бик түбән төшүләрен күрәбез.

Шүрәле турындагы драма әсәрләренең беренчесе – Н.Исәнбәтнең «Кырлай егете» пьесасы. «Шүрәле мифы нигезендә аерым зур күләмле сәхнә әсәрләребез юк. Фольклорчы һәм драматург буларак мин, шушы бушлыкны капларга теләп пьесамны яздым» – ди автор [Исәнбәт, 1980: 194]. Н.Исәнбәт Җирәнбай һәм аның нәселдәшләрен халыкның мифологик хикәятләреннән килгән, Тукай сурәтләгән шүрәлеләрнең җыйнама образлары буларак иҗат иткән.

Күренекеле драматург Т.Миңнуллинның дистә елдан артык сәхнәдә уйналучы «Җанкисәккәем» комедиясендә урманда яшәүче шүрәлеләр хәзерге авыл яшьләренә каршы куела. Шушы ук авторның «Кәрлә – мәктәп баласы», «Гафият турында әкият», «Җен алышырган» әсәрләрендә дә Шүрәле образы шактый тулы ачылган.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г.Тукай, беренче булып, шүрәлене әдәбиләштерә, укучыга җиткерә, аның каләме аша халык хыялында ялангач, таркау, төрле сурәтләрдә йөргән шүрәле укучы алдына нәкъ татар авыллары тирәсендәге урманнарда гына яши торган «милли шүрәле» булып баса. Алга таба шагыйрьләр, прозаиклар һәм драматурглар әлеге мифологик персонажны үз иҗатларында үстерәләр.

Г.Тукай татар фольклористикасында әһәмиятле урын биләгән күренекле галимнәрнең дә бу өлкәгә кереп китүләренә сәбәпче була. Шагыйрь Казан педагогия институты профессоры Хуҗа Бәдигыйнең (1887–1940) фән дөньясына аяк атлавына йогынты ясаган кеше. Мәдрәсә шәкерте Хуҗаны венгр галиме Ю.Мессарош Казанга килгәч, аңа ярдәмче итеп билгелиләр һәм яшь шәкерт зур галим белән Казан арты авылларында халык иҗатын җыя. Егетне Тукай белән таныштыргач, аның эшчәнлегеннән хәбәрдар шагыйрь: «Ә, халык әдәбиятын җыючы кеше синмени әле ул? Нихәл, эшләпә туламы, әллә эшләпәнең төбен тишеп, капчык тектеңме?» – дип, «Хәйләкәр таз» әкиятендәге бер эпизодка ишарә итеп сорый ул. Алга таба да Тукайның Х.Бәдигый белән берничә тапкыр очрашуы билгеле. Тукай Х.Бәдигый туплаган материалларның басылып чыгуын көтә, әмма алар шагыйрьнең вафатыннан соң гына дөнья күрәләр. Шагыйрь белән очрашулары, аның йогынтысында халык иҗатын профессиональ рәвештә өйрәнүгә керешүе хакында Х.Бәдигый үзенең истәлекләрендә язып калдыра [Бәдигый, 1960: 118-122].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г.Тукай халык иҗатын җыюга, бастырып чыгаруга, фәнни өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән кеше. «Халык моңнары» җыентыгы, «Халык әдәбияты» лекциясенең бүгенге

тикшеренүчеләргә дә фәнни нигез буларак хезмәт итүе моның ачык дәлиле. Ә халыкның фольклор мирасыннан рухи көч алып язылган әдәби әсәрләре аннан соң иҗат итүчеләр өчен дә бай материал бирә. Чөнки, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк: "Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул".

Әдәбият:


1. Тукай Г. Халык әдәбияты / Г.Тукай // Әсәрләр, 5 томда. 4 том. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1985: Б. 166-186.
2. Җамалетдинов Л. Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә әкият традицияләре // Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность: в 2 томах, том 2. (Материалы международной тюркологической конференции, проходившей 9-13 июня 1992 года в Казани). – Москва: "Инсан", 1997. – 240 с. – С. 155–157.
3. Исәнбәт Н. Кырлай егете: Пьесалар / Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.
4. Бәдигый Х. Исемдә калганнар // Тукай турында замандашлары. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1960 – 118–122 б.